# КАРАР
## Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Советы

Уразай авылы № 142-10 «08» июль 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җиреле Советының 24.11.2014 ел № 91 «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында (18.08 2015 ел №114, 07.08. 2017 ел №61, 11.10.2018 ел №117 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Салым кодексыныц икенче өлешенә һәм «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турында аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 15.04.2008 елдагы 63-ФЗ номерлы Федераль закон, «Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставы нигезедә,

Уразай авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җиреле Советының 24.11.2014 ел № 91 «Җир салымы турында» карарына (18.08 2015 ел №114, 07.08. 2017 ел №61,11.10. 2018 ел №117 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3) Кадастр бәясеннән 0,1 процент – шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук "Гражданнар үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында"2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата;".

2. Әлеге карар рәсми басма - «Маяк» газетасында басылып чыккан көннән соң бер ай узгач үз көченә керә, әмма 2020 елның 01 гыйнварыннан да иртәрәк түгел.

3. Әлеге карарны район «Маяк» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru. һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http//aznakayevo.tatar.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: А.М.Шәрифуллина